ISSN 0136-7110

ЧАЯН



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

THE MAGAZINE OF SATIRE AND HUMOUR

11

СКОРПИОН * SCORPION

ИЮНЬ * 2015 КАЗАН

САБАНТУЙ 2015

Гаҗәпләнерлек түгел – ике кредитны берүзе тарта бит бу егет!

Сергей АНДРИАНОВ

6-7 нче битләрне кара

АННАН-МОННАН
ИНФОРМ
СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

Матбугатка АКШның Якын Көнчыгыш хәлләрен җайга салу буенча яшерен планы эләккән. Шуның беренче пункты: "Хөсәен белән Каддафины терелтү".

Сораштырулар нәтиҗәсендә 64% Америка студентлары дөнья картасыннан Украинаны таба алмаганнар. Калган 36% дөнья картасының нәрсә икәнен дә белмәгәннәр.

Украинага, Америка инструкторлары килүенә җавап итеп, Новороссийскига Вьетнам инструкторлары килүен хәбәр иттеләр.

Бөтен ил буйлап, балалары мәктәпне тәмамлау хөрмәтенә, ата-аналарның җыелышлары булып узды. Керү – түләүсез. Чыгу 3 меңнән 5 меңгә кадәр иде.

Кулланучылар хокукын яклаучылар, рекламага нихәтле күп акча китүгә карап, колбасада итнең азрак булуын ачыкладылар.

Коммуналь хезмәтләр өчен түләмәү сәбәпле, суд приставлары «Дом-2»-ны ябарга карар кылдылар.

Хастаханәләргә, бәяләр «тешләве» аркасында, пенсионерлар тула башлады.

Югары уку йортларында яңа өлгедәге зачеткалар куллану кертелә – билгеләр прейскурантлар аша ачыкланачак.

Хәзерге яңа йортларда проектировщиклар санузел белән уку залын берләштереп эшләүне күздә тоталар.

Культурист ел буе срогы чыккан протеин кулланып, мускул кабарткан.

Фатирда эләктерелгән карак бәдрәфкә кереп бикләнгән, ләкин унитаз аша юылып кача алмаган.

Сколковода бернинди участковый таба алмаслык наносамогон аппараты уйлап тапканнар.

Тырмалар ясый торган фабрика ОТКга авыртуларны сизмәүче специалистны эшкә чакыра.

Эчмичә тора алмаучы алкоголик лимонадтан агуланган.

Патологоанатомнар белән аягын сузучылар арасында ярышлар булып узды.

Психологлар, әкиятнең ахырыннан кирегә таба укысаң, балаларның йокыларыннан әкренләп уянуын ачыклаганнар.

Чибәр кыз тарафыннан өенә чакырылган сантехник торбадан агып торган суны барыбер туктата алмаган.



Вәдүт ЯКУПОВ

Мәктәп ихтыяҗлары

Улым мәктәптән кайткач, болай диде:

– Укытучы белән директор әти-әниләребезнең кайда эшләгәннәре һәм мәктәпкә нинди ярдәм күрсәтә алулары турында белеп килергә куштылар. Миңа нәрсә диярга?

– Минем әти прокурор дип әйт, – дидем мин, күз дә йоммыйча.

– Синнән нинди прокурор, син бит өченче разрядлы җыючы-слесарь, – дип, көлеп куйды хатыным.

– Әти безнең сыйныфта инде болай да биш прокурор, ике судья һәм бер икътисадый җинаятьләр белән көрәшү идарәсе башлыгы бар, – диде улым.

– Алай булгач, минем әти – «вор в законе» диген...

Икенче көнне кич белән улым миңа болай диде:

– Беләсеңме, әти, безнең мәктәп тә, сыйныф та ата-аналар ярдәменә мохтаҗ түгел икән.



Виктор ФЁДОРОВ



Авыздан чыпчык

Авария нәтиҗәсендә очраклы рәвештә беркем дә һәлак булмады.

Ул матур ireннәре белән йомшак кына елмаеп куйды.

Тормышыгызны куркыныч астына куймас өчен тирән суда түгел, ә ярда йөзегез.

Госпитальдән кайткач, ул барыбер култык таяклары белән очарга өйрәнде.

Солженицын рус телен «шмон», «борзой», «стукач» кебек сүзләр белән баетты.

Капкачының аяк арасындагы соңгы киртәне кичеп, туп капкага очып керде.

Проблема шунда ки, авырулар даими рәвештә табибларны эштән аера.

(радиотапшырулардан)



Хөрмәтле Чаян! Билгеле булганча, һава торышын фаразлау – гаять четерекле эш. Ә телевидение прогнозлары – бигрәк тә. Әйтик, диктор аяз һава игълан итә – тәрәзә артында ишеп яңгыр ява башлый. Вәгъдә ителгән яңгырларны көтәбез – тышта кояш яндыра. Ә соңгы вакытларда телевидение метеорологларының фаразлары һаман саен сирәгрәк тормышка аша...

Җ. ГАЛӘВИНА

МАМАДЫШ

– **Чынлыкта исә алар тормышка аша,** – диде Шомбай ага, укучының хатын укып чыккач. – **Ләкин бөтен кеше өчен дә түгел. Ә бары тик алар рекламалаган таблеткаларны кулланганнар өчен генә.**



Людмила АЛАНЛЫ

“БЕСПЫЛАТНЫЙ” АВЫЛ

Авылда бит бәрәңгесе “бушка”,
Кишер, суган “җиңел” бирелә,
Сөт, каймагы күпләп агып тора,
Бар нәрсә бар авыл җирендә,
Дип сөйлиләр шәһәр өендә...

...Мең тир түгеп җирне сөрә алсаң,
Иренмичә генә эшкәртсәң,
Тырмаласаң,
чәчсәң,
сулар сипсәң,
Сирәкләсәң,
кертсәң ашлама,
Көзен урып-җыю башлана:

“Беспылатно” килә бәрәңгесе,
Сөте,
мае,
катык,
каймагы...
...Ләкин беркайчан да шәһәр халкы
Фатирларын ташлап кайтмады.
Шәһәрдә ятты,
Бөтен нәрсә “беспылатный” диеп,
Төяп китте,
Һәм авылны ихлас мактады.

Карак кунаклар

Озакка дип чит илгә чыккан россиялеләргә җирле законнарны үтәргә туры килә. Хәтта иң мәгънәсезләрен дә. Мәсәлән, Англиядә кичке тугыздан соң хатыннарны кыйнау тыела, Америкада – «небоскрёб» түбәсеннән сикергәннәрне үлем җәзасы көтә, ә Сингапурда өй эчендә ялангач килеш йөрергә ярамый. Бу яктан чит ил кешеләренә Россиядә яшәү күпкә уңайлырак. Безнең законнар ачык һәм аңлаешлы: үтермә, талама, көчләмә, хакимияткә каршылык күрсәтмә – һәм тынычлап яши бир. Ләкин шуңа да карамастан, бу тәңредән иңгән диярлек кагыйдәләрне бозучылар табылып тора.

Татарстанда ун елдан артык бер Һиндстан гражданины мошенничество белән шөгыльләнгән. Үткен егет, медицина университеты студенты, ашлык «саткан», алынган машина правaларын «кайтарган», арзан бәягә иномаркалар «табып биргән», чит фатирлар саткан, үзен ФСБ хезмәткәре итеп таныткан, хәтта кара мәрмәр табарга вәгъдә иткән. Уку аның күпкырлы «эшчәнлегенә» һич кенә дә комачауламаган. Әгәр ул узган ел полициягә эләкмәгән булса, әле тагын ничә ел беркатлы кешеләрне төп башына утыртып йөрер иде. Алданган гражданнар шома индусның кыланышларыннан күргән зыяннарын 10 миллион сумга бәяләгәннәр.

Ә 62 яшьлек Манук Симонян исә криминаль эшчәнлеген мәхәббәт юнәлешендә җәелдергән. Үзенең күрекле кыяфәтеннән ул бик оста файдаланган. Шул аның башына җиткән дә. Гади әрмәннән грек вице-консулына әйләнеп, сөюгә сусаган күп кенә ханымнарның йөрәген яулаган. Бөдрә чәчле, янып торган кара күзле мәһабәт «дипломат» нинди генә хатынның башын әйләндермәс икән? Һәм кайнар канлы сөю остасы чираттагы сөяркәсенә Эллада уты белән җан өреп, иртүк югала торган булган. Ә ялкынлы мәхәббәт хисләреннән эрегән ханымнар «вице-консул»ның гына түгел, өйдәге акчаларның да юкка чыгуына төшенгәннәр.

Әрмән грегыннан аермалы буларак, күрше илдә туган өч ир кеше гади талау белән көн күргән. Питрәч районында алар Екатеринбургтан килгән кунакның 400 мең сумын талап алганнар. Җинаятьчеләрне бик тиз тотканнар, хәтта зыян күручегә акчасын да кайтарып биргәннәр.

Татарстан полицейскийларын намуслылыкка тикшереп карарга булган Таҗикстан кунагы да җинаять статистикасын тулыландырган. Россиядә законлы рәвештә яшәве турында бернинди дә документ күрсәтә алмагач, ул полицейскийга 5 мең сум «төртергә» маташкан. Моның белән ул киләчәк тормышын хәл иткән: легаль булмаган мигранттан тулысынча легаль «утыручы»га әверелгән.

Узган елда Татарстанда гына чит илдән килүчеләр тарафыннан 423 җинаять кылынган. Шулай итеп, Россия төрмәләренә барлыгы 30 мең «кунак» кереп утырган. Хәтта вак җинаятьләр өчен утыртмыйча, аларны ватаннарына кайтарып җибәрергә дигән тәкъдим дә кертелә, чөнки үзебезнекеләргә урын җитми башлаган!

Быелның гыйнвар аеннан эшләүче мигрантлар өчен рус телен, Россиянең тарихын һәм законнарны белү буенча имтихан кертелде. Хәзер Россия парламентында ничә палата, Владимир кенәзнең кем икәнен белмәгән килеш итле бөккәннәр ясау, такси йөртү һәм базарда сәүдә итү кыенлашачак. Хакимият шулай итеп булса да «халыкларның зур күченүе»нә тәэсир итәргә тели. Югыйсә кайберәүләрнең иреклe тормышлары төрмәгә күченү белән тәмамланачак.

Людмила САФИУЛЛИНА



Валентин ДРУЖИНИН


Валерий ТАРАСЕНКО



Виталий ПОДВИЦКИЙ



Николай ВОРОНЦОВ





• • •

– Куба Рәсәйгә 30 миллиард доллар бурычлы. Хәленә кереп, гафу итикме?!

– Африка 20 миллиард? Нинди чутлашулар булырга мөмкин дуслар арасында!

– Украинаның Рәсәйгә 40 миллиард доллар бирәчәге бар. Без партнерларның катлаулы хәлләренә зур ихтирам белән карыйбыз!

– Хезмәт ветераны Гәрәй улы Бари Рәхимов ипотека буенча айлык түләвен 10 мең сумга кичектергән? Коллекторлар! Сакчылар!

• • •

Порошенко:

– Рәсәй безнең ирек сөючән демократик илебезне буа, хәтта сулыш алырга да ирек бирми... Мең куб газ өчен 200 доллар гына түләп буып булмый микәнни соң безне, ә?..

• • •

Охшаш кешеләр конкурсы вакытында, Алла Пугачёва булып, яшерен генә Алла Пугачёва үзе дә катнаша. Ләкин җиңүче итеп барыбер жюри рәисе хатыны танылa.

• • •

Хөрмәтле күп катлы, элиталы йортта яшәүчеләр!

Җылыуткәргеч трассасы планлы ремонт чаралары үткәрелү сәбәпле, сезнең йортта 20 майдан 20 июньгә кадәр элиталы су җибәрү туктатылып торачак. Шуңа күрә элиталы гафу итүегезне сорыйбыз. Элиталы ТСЖ.

• • •

Тәҗрибәле җитәкче клавиатура тавышының яңгырашы буенча үзенең кул астында эшләүченең нәрсә уйнарга маташуын сизә ала.

• • •

Олигарх кичен өенә кайта. Хатыны:

– Ашыйсың киләме?

– Ә нәрсә бар?

– Омар, икра, бургунд шәрабы...

– Эх, суда гына пешерелгән бәрәңге ашасаң иде дә, куас белән эчеп җибәрсәң иде!

– Ә син башка ирләр кебек эшлә, шул вакытта сиңа бәрәңге белән куас булыр!



Күңелле Сабантуй

СЕЗ БЕЛӘСЕЗМЕ?..

...Сабан туе мең елдан артык бәйрәм ителә. Аның турында 921 елда Болгар дәүләтенә Багдадтан илче булып килгән Ибн Фадлан язып калдырган.

...Чабышта беренче булып килгән атның муенына чигүле затлы тастымал бәйли торган булганнар. Ә җайдакның һәм чигүче кызның исемнәре киләсе Сабан туена кадәр халык теленнән төшмәгән.

...XX гасыр башында татар газеталарында кайнар бәхәс барган: Сабан туе кирәкме, юкмы? Мөселман руханилары аны әхлакый таралуга китерә, дип санаганнар, һәм бәйгене дини йолаларга кайтарып калдыруга чакырганнар. Ләкин демократик интеллигенция һәм халык бәйрәмне саклап кала алганнар.

...Совет заманында халык бәйрәменә сәяси төсмерләр кертергә дә тырышып караганнар. Мәсәлән, Арча Башкарма комитеты мөрәҗәгатендә Сабан туен бәйрәм итү «Ленин васыятьләрен тормышка ашыру – шәһәр белән авылның бердәмлеген көчәйтү» дип аталган. Ә 1932 елда бәйрәм «Хезмәт һәм оборона бәйрәме» исеме белән үткәрелгән.

...Сабан туен бәйрәм итүдә төрле вакытларда Россия президентлары да катнашкан. Ельцин чүлмәк ваткан, ә Путин катык салынган таздан авызы белән көмеш тәңкә табып чыгарган.

Илдар НӘФИЕВ





Александр АЛЁШИН



Виталий ФЕОКТИСТОВ



Илдус АЗИМОВ

Фәнзаман БАТТАЛ

ШАЯН АВЫЛ БӘЙГЕСЕ

Монда көрәш, монда чабыш,
Күпме сый, күпме уен!
Мәзәкләр белән бизәкле
Якташлар Сабан туен!

• • •

Күрегез: кабык торбадан
Шуып чыкты Миначтин.
Шомарган бит,
"толкач" булып,
Дөнья гизә торгачтын!



Уратып алган бер төркем
Биек, шома колганы.
Йөри шунда Сәрхуш Сәмәй,
Әрле-бирле тулганып:

– Аек булсам, очында ук
Утырачак мин аның!
Кемдер әйтте:
– И, җаныем,
Күрер идек бер, ичмасам,
Бер көн аек булганың!



Нык суктылар
капчык белән...
Барып төште... Аптырый...
Тик шулай да "үз капчыгын"
Чәлеп китте Гаптери.

– Гаптери – ай-һай! – диләр. –
Гадәте... алай! – диләр.
Гел капчыклап урлый торгач,
Остарды, малай! – диләр.

• • •

Мәчтүрәттәй сөйләп тора,
Тавык боты кимереп:
Сара кызы үлә инде
Кияү эзләп, тилмереп...

Ә минем кыз – үзем кебек! –
Бәхетле булды, малай!
Әлхәмделиллаһи шөкер,
Җиденче ирен кыйнай!

• • •

Ике чыпчык сугыша икән,
Ул төштә дә яклаш бар.
Әмма-ләкин Сабантуйда
Яклашмыйлар якташлар.

Хәрәмләш тә гөнаһ монда –
Сабантуй булсын якты!
Тагын бер тапкыр күзәтик
Ярышлар барган якны:

Аргы башта – чүлмәк вату.
Сирәкләр генә вата.
Күз бәйләүче Фәрхетдингә
Ялварып тора Гата:

– Игелек җавапсыз калмас,
Күрерлек итеп бәйлә...
Әйтте Фәрхи, кысып бәйләп:
– Юмалап торма, әйдә!

Сабан туе – кантур түгел,
Тыкма монда блатны –
Өйрәнгәнсең кантурыңда
Алдап безнең братны!..

• • •

Бер як читтә ярыш бара –
Су ташу ярышлары.
Көянтәле җиңгиләрнең
Җилдертеп барулары!

Ферма мөдире Сәйфетдин
Сикереп куйды мәгәр:
– Эх, боларның барысы да
Миндә эшләсә әгәр,

Файдалана белер идем,
Бу житезлек-көчләрен!
Җанга тимәс иде ватык
Автоэчергечләрем...



Алыптай гәүдәле Зиннәт
Быел да батыр калды –
Алаша хәтле тәкәне
Иңенә алып салды.

Фәрхенур чыкты атылып:
– Кем җитә минем иргә!
Һәм... ирен күтәреп алды
Тәкәсе белән бергә!

Бу дөньяда иң көчлесе –
Мәхәббәт икән бит ул!
Зиннәт кебек егетләрне
Мәһабәт иткән бит ул!




Сокланудан: шатланудан
Мәйдан гөр килеп тора.
Шаянлык тулы йөзләрдән
Нурлар бөркелеп тора.

...Монда көрәш, монда мәзәк,
Күпме сый, күпме уен!
Кызыклар белән бизәкле
Якташлар Сабан туен!







АХИР

ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР

ХӘБӘРДАР

Баш редактор Роза Туфитуллова редакция хезмәткәрен, ягъни шагыйрь Мөдәррис Әгъләмне чакырып ала да болай ди:

– Мөдәррис, синең турында начар хәбәрләр йөри.

Хәер, Мөдәррис тә аптырап калмый:

– Нишләп андый начар хәбәрләр турында мин бер дә хәбәрдар түгел соң? – ди.

"ҮЗЕПЕЗ" ДИП ТОРАБЫЗ

Чаллыда яшәп иҗат итүче танылган язучы Вахит Имамов Татарстан Язучылар берлеге рәисе, шагыйрь Илфак Ибраһимовка (Мөхәммәт Мирза) телефоннан шалтырата икән.

– Быел нинди даһига Тукай премиясен бирергә җыенасыз инде?

Телефоннан озак кына дәшмиләр. Бераздан соң рәиснең шат һәм көр тавышы яңгырый:

– Бер мәзәк искә төште. Авылда бер чуаш мактана икән: "Безнең авылда өч изге бар, берсе аның югары очта чур Иван, икенчесе түбән очта пүр Иван!" "Ә өченчесе кем?" – дип сорыйлар моңардан. "Үзепез дип торабыз!" – дигән чуаш. Менә шуннан аңла инде, Вахит дус...

ЯЗУЧЫДАН ДА БАЙ КЕШЕ ЮК

Бервакыт шулай трамвайдан төшкәндә мине контролерлар тотып алды. Эшсез йөрим. Кесәдә бер тиен дә акча юк.

– Штраф! – ди контролер. – Түлә!

Нишләргә? Язучылар берлеге әгъзасы дигән булып, моңа кызыл тышлы кенәгәмне дә суздым.

– Сезгә ташламалар юк, язучылар түләп йөрергә тиеш! – ди бу.

– Ярар инде, брат, җибәр, без язучылар ярлы инде, акчасыз! – дигән булам.

– Сезме ярлы? Язучылардан бай кеше юк ул. Мин бер язучыны беләм...

– Кемне? – Шул вакыт мин нигәдер депутат шагыйрьләрне күз алдына китердем.


– Ркаил Зәйдулланы беләсеңме?

– Белмичә... Минем ахири бит ул...

– Менә ул бай!

– Каян килеп таптың бай кеше – әле кичә генә миннән ун тәңкә акча сорап алды. Бирмәгән булсам, хәзер сиңа уч тутырып штраф түләр идем!

Валентин ДУБИНИН



Хамис ГАРИПОВ

ХАТЫН МЕНГӘН МУЕНГА...

Матриархат дигәннәре
Килде безнең елларга!
Хатын муенга утырды,
Белмим нәрсә уйларга?
"Төш!" – диеп селким югыйсә,
Никтер, бер дә тыңламый,

Башка суккалап утыра
Әйткәнемә карамый!
Нишлисең, дөньясы шундый,
Хатын – баш, ирләр – муен!
Үзгәрерме бу тормышлар,
Ә хәзергә – бик кыен!

Игорь КИЙКО




КАРИКАТУРИЗМ

Николай КАПУСТА



Игорь КИЙКО



Михаил ЛАРИЧЕВ



• • •

Американың Гавай утрауларындагы отеленә бер байгура чаңгы күтәреп килеп керә.

Әфәндем, – ди аңа отель хуҗасы, – безнең утрауда беркайчан да кар булмый. Чаңгы нигә кирәк булды сезгә?

– Юкка борчыласыз, – ди кунак, – аэропортта кар төялгән ике махсус самолёт тора.

Валерий ТАРАСЕНКО



Валентин ДУБИНИН

ШИГЪРИ ДУЭЛЬ

Рашат Низами:

Яз.
"Торыйк... Торыйк..." диеп саф татарча
Сәлам бирә безгә торналар...

Алмаз Хәмзин:

Күз.
Гомер үтә, ләкин телен белми,
Без үстергән газиз балалар.

Р. Н.:

Еллар.
Күңел һаман унҗидедә икән,
Еллар гына... бераз картайган.

А. Х.:


Юллар.
Офыкларны күрер күзләр беткән,
Капшап йөрим – юллар тарайган.

Р. Н.:

Онык.
Сөбханалла! Сүзләр яралганда
"Ән-нә..." диеп телең ачылсын!

А. Х.:

Бабай.
Әстәгъфирулла! "Здравствуй, дед!" – дип
Ярып салды онык русчасын.



Вячеслав ШИЛОВ



Әнвәр МӘГЪСҮМОВ

Өч аштан әдәп

Гаделшин ресторанга тамак ялгарга керде.

– Кем әзерләде моны? – гаҗәпләнеп сорады ул официанттан, беренчегә бирелгән ашны кабып карагач.

Кухнядан кулына зур соскыч тоткан әзмәвердәй повар килеп чыкты.

– Мин, ә нәрсә?

– Юк-юк, бик тәмле булган, – диде клиент, елмаерга тырышып.

Кыздырма китереп куйдылар.

– Нинди үкчәдән ясадыгыз моны? – диде Гаделшин, үзен көчкә тыеп.

Кухня ягыннан ярты метрлы пычак тоткан олпат гәүдәле абзый күренде.

– Нәрсәдән риза түгел? – диде ул күкрәү тавышы белән.

– Бөтенесе дә бик искиткеч яхшы, – дип елмайды Гаделшин, теш үтмәс кисәкне чәйнәгән кыяфәт ясап.

– Ә монысы нәрсә була тагын? – диде ул, алдына кесәл китереп куйгач.

– Яңа җыелган тропик фруктлардан кесәл! – дип ыржайды киң бәдәнле җирән егет. – Үзем җыйдым! Минемчә, телне йотарлык тәмле чыккан, шулай бит?

– Әлбәттә, – дип бүлкелдәде Гаделшин, кесәлне авызында тоткан килеш.

Икенче көнне ресторанга ул өч кырыс йөзле бәндә белән килеп керде.

– Нинди меню телисез? – дип сорадылар кухнядан чыккан әзмәвер, олпат абзый һәм җирән егет.

– Менюмы? Беренчегә – салымнарны тикшерү – Гаделшин юлдашларының берсенә ымлады. Икенчегә – янгын инспекциясе, – диде ул, икенчесенә карап. Ә өченчегә – санэпидемнадзор, – ул бармагы белән өченчесенә төртеп күрсәтте.

...Шул вакыттан алып ул рестораннда ашлар искиткеч тәмле, ә хезмәт күрсәтүчеләр – әдәпле һәм итагатьле булып китте. Бигрәк тә анда Гаделшин килгән чакта.

Нәсимә БӘХТИЕВА

ЭТ – ЭТКӘ, ЭТ – КОЙРЫККА

– Сез, нәрсә, Облздрав приказлары белән танышмадыгызмыни? Страховой медицина турында беренче тапкыр ишетәсезме? – дип кычкырды баш табиб өлкән шәфкать туташларына.

– Әгәр поликлиникага йөреш кимегән икән, бу финансированиене кисәчәкләр дигән сүз! – кызарынып-бүртенеп дәвам итте ул.

– Соң җәй өчен гадәти хәл бит инде бу, – дип каршы килергә тырышып карадылар аңа. – Менә көзләр җитәр, җәй буе бөгелгән билләр сызлый башлагач, халык регистратурага ябырылачак. Коридордан үтеп булмаячак. Ә Төркиядә ял итеп кайткannар венерологка талон ала алмыйча интегәчәк.

Дөресен әйткәндә, баш табиб үзе дә сәгать буе аның тетмәсен теткән өлкә министрына хәлне шулай ук аңлатырга маташкан иде. Ләкин тегесенең оптимизация планы начар үтәлгән өчен Мәскәүдән койрыгын борганнар иде.

– Аңладым. Бездә гаеп бар. Игътибар җитмәгән. Контрольдә тотачакмын, – дип хәбәр итте Мәскәүгә өлкә министры.

Шулай итеп, ризасызлык дулкыны поликлиника баш табибына килеп җитте. Ул, әлбәттә, бүлек мөдирләреннән башларга кирәклеген аңлый иде. Ләкин ул үзләре өчен дә, түләүле медицинага качкан егетләр өчен дә эшләүче пенсионерларны сүгәргә базмады. Шуңа күрә ул моның өчен өлкән шәфкать туташларын сайлады.

Баш табиб кабинетыннан пешекләнгән тавыклар кебек чыккан өлкән шәфкать туташлары бөтен ишеткәннәрен гади медсестралар өстенә түкте. Тегеләре исә, үз чиратларында, реформаларның бер урында таптануын тиешле срокларда дәваланып чыгарга теләмәгән авыруларга кайтарып калдырдылар. Медицинадагы бөтен буталчыклык өчен янәшәдә тәрәт савытларын сөрткәләп утырган санитарка Розага җавап тотарга туры килде.

Иренә бөтен җыелып килгән үпкәләрен әйтеп салуын күз алдына китереп, ул сулышы кабып өенә очты. Ләкин барып чыкмады. Иренә – ЖКХ электригына – үз нәчәлнигыннан илнең энергетика системасының таркалуы өчен бик каты эләккән икән. Шуңа күрә мәктәптә укучы уларын җәзалау гына кала иде. Нәрсә өчен? Гадәттәгечә, «өчле»ләр, җыелмаган савыт-саба өчен... Кыскасы, малайны бер атнага компьютерсыз калдырдылар. Малай, ачудан, аяк астында уралып йөргән Актүшкә тибеп җибәрде. Мондый хыянәтне көтмәгән Актүш чинап җибәрде һәм усалланып, йокымсырап яткан мәчене тешләп алды. Мәчегә тешләрдәй зат юк иде, аңа диван астына кереп качасы гына калды.

Ә беркемне дә тешләп булмау – иң ачы рәнҗү бит ул...



Николай ВОРОНЦОВ

Нәҗибә САФИНА

ЗАМАНА ТУКМАКЛАРЫ

Укымыйлар – язалар.
Яратмыйлар – азалар.
Зифа буйлылар юк инде,
Хәзер бар да тазалар.

Яшәмиләр – уйныйлар.
Яшибез дип уйлыйлар.
Сөйлим дип, сүгенәләр.
Бар нәрсәгә мырлыйлар.

Кадер юк туган җиргә,
Ни-нәрсә әйтим кемгә...
Чыгалар хәзер иргә
Бары берничә көнгә.

Балалар үсә ятим, –
"Гаепле түгел" хаким.
Хатын-кыз сата үзен,
Инде капламый йөзен.

Эшләми арып-талып,
Беттек хәерче калып.
"Нишләргә" – дип тик тора,
Бик сәер хәзер халык.

Кемгәдер тән сакчысы,
Миллион-миллиард акчасы.
Кемдер саклый җан гына,
Җирдә бары сан гына.

Ходай да әйтми сүзен,
Үлмәгәндер үлүен...
Шул хәлләргә дәшмәгәнгә,
Ансы да йома күзен.

....

Бәндәгә баш имәгез! –
Алла юктыр димәгез!
Иманга килә башлыйсыз,
Төпкә китсә көймәгез.

Ыңгырашабыз шуңа,
Ә депутатлар шома.
Уйнап сайланган хакимнәр
Халыкны салды шомга.

Вакыт инде уйларга,
Чик куйыйк уеннарга,
Тагы бер кат салынганчы
Элмәкләр муеннарга.



ЗАКОНЛЫ "РОМАШКА"

Хөрмәтле редакция! Законсыз уен автоматлары бизнесына каршы көрәш күптән барса да, уйнарга теләүчеләр кимемәде. Җиңел акча оту өмете белән кемнәрдер Интернетта казынса, икенчеләре тиз арада акча юнәтү мөмкинлеген бирә торган лотереяда катнашырга чакыручы "лотоматлар"га ябырылды. Автоматлар элеккегеләреннән берни белән дә диярлек аерылмый – алар шулай ук халыктан акча суыру өчен көйләнгән.

Шәһәрнең кеше күп йөри торган урыннарындагы "Ромашка"лар электрон программалары белән җиһазландырылган лотерея билетларына әверелде дә куйды. Бәхет сынап карарга теләүчеләр саны да арта бара. Ник дисәң, барысы да законлы ич. Өстәвенә, аларда күбесенчә, элеккеге кебек үк, тышкы кыяфәтләренә караганда акчалары ташып тормаган кешеләр уйный. Теләсә кайсы "геймер"дан акча ота алдыңмы дип сорасаң, шундук җавабын да ишетәсең: "Әлбәттә! Ике тапкыр берәр таңкә!"

Яңа лотерея модасын тыюны таләп итүчеләр дә күбәя бара. Уен автоматларына каршы көрәш бик ансат түгел шул. Әйтик, Яшел Үзән автовокзал каршында торган әлеге автоматны еш кына экспертизага алып баралар. Ә суд һәрвакыт "Ромашка"ны законлы дип таный.

В. ФӘЙЗУЛЛИН

ЯШЕЛ ҮЗӘН

МӘНСЕЗЛЕК

Хәзер кайсы гына оешманы алма, компьютер һәм информацион технологияләрсез эшләүне берничек тә күз алдына китереп булмый. Файдаланмаган кеше юктыр хәзер аны. Әмма, иң алга китешле техника да ялгыша икән. Әйтә алмыйм, минем очракта техника ялгыштымы әллә техникага сылтаган кеше ялгышымы... Бәлкем, серле кара көчләр уеныдыр. Шәхсән үзем саннар магиясенә ышанып та бетмим.

13 майда Вишневский урамында урнашкан республика офтальмология клиникасында тикшеренү үттем. Өйгә кайтып карасам, исем-фамилиям минеке түгел. Кире барырга туры килде. Регистратурада мине компьютер ялгышкан дип ышандырдылар. Шундук яңа карточка тоттырдылар. Тикшеренү нәтиҗәсенә тагын күз салсам – күзем маңгайга менде. Беркайчан да борчымаган күзгә ике ел элек инсульт һәм операция кичергән дип язып куйганнар.

Өченче тапкыр барырга туры килде. Бу очракта да башка кеше диагнозын биргән компьютер гаепле булып чыкты. Компьютер базасында минем анализларны эзләп таба алмагач, тикшеренүне яңадан үттем.


Менә хәзер кем гаепле: компьютер яисә игътибарсыз кеше гаебеме икән дип уйланып утырам. Бәлкем, "13" саны гаепледер? Ирексездән хорафатларга ышанырсың монда...

Г. СӨНГАТУЛЛИНА

КАЗАН











• • •

– Әйдәгез, «ватык телефон»лы уйныйбыз.

– Әйдәгез!

– Шар-р-рт...

– Син минем телефонны ваттың бит!



Сергей АНДРИАНОВ

Абау!

ИПОТЕКА КОРБАННАРЫ

«Җирдә берни дә юк мәңгелек», – дигән шагыйрь. Социаль ипотека буенча төзелгән йортлар да моннан чыгарма булып кала алмый, әлбәттә. Тик кайчагында аларның эксплуатацияләү срогы бик кыска булып чыга. Казанның Торак-коммуналь хуҗалык комитеты башлыгы Искәндәр Гыйниятуллин белдерүенчә, бүгенге көндә шәһәрдә соңгы ун ел эчендә төзелгән бер дистә чамасы җимерелеп баручы йорт исәпләнә. Аларның тышлыгы куба, стеналарында ярыклар барлыкка килә. Шундый йортларның берсен хәтта капремонт программасына кертергә туры килә. Прокуратура гаепләләрне эзли, кредит алучылар башларын тота. Торак өчен чирек гасыр дәвамында түлисе бар, ә йортыңның түбәсе хәзер үк менә-менә ишеләм дип тора...

ТОТЫЛМАС КАЧКЫННАР

Һичшиксез, армиядә хезмәт итү – һәр ир-егетнең мактаулы бурычы. Ләкин һәр егет тә бу шигарь белән риза түгел. Генштаб мәгълүматларына караганда, көзге призывтан 210 мең призывник качып калган. Бу бит 30 дивизия дигән сүз! Өстәвенә, алты мең егет повестка алган, ә хәрби комиссариатка килмәгән. «Качкын»нарны стройга бастырыр өчен нинди генә чаралар тәкъдим ителмәгән: өстәмә 13 процент салымнан алып рәсми рәвештә акча түләп, хәрби хезмәттән азат ителүгә кадәр. Әмма аларны җавапка тарту да, 200 мең штраф та куркытмый – «качкын»ны тотарга кирәк бит әле. Менә шулай, ватанның изге чакыруы саңгырау белән сөйләшү булып кала бирә.

МИЧТӘН КИЛГӘН СИГНАЛ

Австралия астрономнары бөтен дөнья алдында рисвай булган. Унҗиде ел дәвамында алар галәм киңлекләреннән килгән серле сигналны өйрәнгәннәр. Беренче тапкыр аны узган гасырда тоткан булганнар, аннан соң ул вакыты-вакыты белән икешәр минут буе кабатланып торган. Бу күренешкә хәтта перитон – оча торган әкияти болан – дигән матур исем дә тапканнар. Ә күптән түгел обсерваторияне яңа аппаратлар белән җиһазлаганнар. Алар ярдәмендә «гасыр табышмагы» бик тиз чишелгән. Сигналны обсерватория кухнясыннан... микродулкын миче җибәреп торганлыгы ачыкланган. Сүндергән чакта мич менә шундый «перитон» ясый торган булган.

Марс ШАБАЕВ

КАРТАЙГАН ЯШЬ ЯЗУЧЫ МОНОЛОГЫ

(Нәширнең якасыннан алып)

Нигез, диләр, фикер кирәк, диләр.
Фикерем бар, шундый нигездә:
Утыз еллап язам! Шул җитмиме?
Темпланнан урын бир безгә.

Бездә хөрлек.
Матбугат иреге:
Тулы хокукым бар язарга.
Ә сез этәрәсез яшь авторны.
Этәрәсез кайсы базарга?
То-то!

Уртачарак булса язганнарым:
Ул – уртакул, имеш, примитив.
Бул син, имеш, халкың җылынырдай
Ут табарлык горур Прометей!

Прометей ул – берәү!
Ул да мифик.
Ә без – күбәү.
Ә без – яшибез.
Хатын да бар, балалар да ишле...
Тик түзәбез әле, дәшмибез.
То-то!

Күктән шедеврлар көтәсездер.
Ә без – монда,
Ә без – уртада.
Кирәк булса, керә алабыз без
Җитәкчеле олы йортка да.

Әйтерсең лә, үзләре бик талант!
Язучылар, имеш, членнар.
Тукай член түгел бер дә әнә...
Тукай – фил ул!
Ә сез – чебеннәр.
То-то!

Фил таләбе безгә куясызмы! –
Бу бит безобразие! Күз буяу...
Халык күзе һәм колагы – без бар,
Без бар әле монда,
Без уяу!
Өч көн срок сезгә уйланырга
Последствиеләре турында.
Йә басасыз минем җыентыкны,
Йә... җиткерәм тиеш урынга.
Хушыгыз!


(Ишек бәреп чыгып киткәндә
Штукатур коела идәнгә.)

Суфия НАСЫЙРОВА, «Чаян» № 11, 1975



– Вәт яшьләр китте, әй – ветераннарга бернинди ихтирам юк!

Виктор ИГНАТЬЕВ, «Чаян» № 11, 1978.



– Без аларны Сабан туена экстремаль шартларда әзерләргә булдык.



КӨЛКЕ КАМЕРАСЫ



Олег ПРЯНИЧНИКОВ

Үз ысуллы

Караңгы төндә ир кешене ике билгесез бәндә туктата.

– Акчаң бармы? – дип сорый алар.

– Юк шул, – ди ир кеше, гаепле кыяфәт белән. – Әле генә талап алдылар.

– Алайса без сине кыйныйбыз, акчасыз, болай гына.

– Мине кыйнадылар инде, – ди ир кеше, борынын тартып. – Шушы ишегалдында, бер минут элек. Алар икәү иде... Бик оста кыйнадылар – тәндә эз калдырмыйча. Акчаны да би-и-ик күп алып калдылар...

Бандитлар селәгәйләрен йотып куйды.

– Ярый. Иртәгәдән башлап сиңа бездән башка беркем дә кагылмаячак. Ә тегеләр белән хәл итәрбез... Аңладыңмы?

– Аңладым, – диде ир кеше һәм икенче караңгы ишегалдына юнәлде. Анда да ике бәндә аның юлына аркылы төште.

– Акчаң бармы?

– Бар иде. Би-и-ик күп! Әле генә талап алдылар. Өстәвенә, кыйнадылар да. Сезнең ишегалдында. Икәү иде алар.

– Нәрсә, аларга үз ишегаллары җитми микән? Ярый, хәзер без аларны ерткалап ташлыйбыз... Кирәкләрен бирәбез без аларның, – диде бандитлар.

– Беләм, беләм. Һәм миңа сездән башка беркем дә кагылмаячак...

Икенче көн иртән хастаханәдә дүрт каты имгәнгән бандит барлыкка килде. Алар бер-берсен танымаслык дәрәҗәдә изгәннәр иде...

Ә теге ир кеше кичке вакытта караңгы ишегалларында йөри бирә. Полиция капитаны Куянов җинаятьчелек белән көрәштә үз ысулларын файдалана...



• • •

– Гражданин, сез нигә этегезне авызлыксыз йөртәсез?

– Иптәш сержант, ул авырый, тиздән үләчәк, әзрәк шатланып калсын дигән идем.

– Нәрсә белән авырый инде ул?

– Котыру чире белән...





Валерий ТАРАСЕНКО



ЧУАР пресса

ФОТОНЫҢ КӨЧЕ

Англиядә яшәүче тизлек һәм машина ясаучыга почта аша машинасының фотосы һәм 40 фунттка штраф квитанциясе килеп төшә. Штрафны түләү урынына ул полициягә 40 фунт төшерелгән фото җибәрә. Берничә көннән ул яңадан хат ала. Бу юлы конвертта кул богаулары төшерелгән фото була. Штраф шул минутта ук түләнә.

СҮЗ БИРДЕҢМЕ – ҮТӘ!

Американың Детройт шәһәрендә ике коралланган карак кибеткә бәреп керә. Сатучыны һәм сатып алучыларны куркыту өчен, берсе: “Бер кешегә дә селкенмәскә!” – дип кычкырып җибәрә. Иптәше кассага таба юнәлгәч, ул сүзендә торып, аны атып үтерә.

АВЫРУ ФАНТАЗИЯ


Европада сексуаль меньшинстволар җәмгыятьтәге дәрәҗәләре белән ахыргы урыннарда тормыйлар. Француз юмористик журналы тирәсендәге җәнҗал әле тынып җитмәгән, ә Парижда яшәүче карикатурист һәм мультфильм төшерүче кызык эш эшләгән. Янни Галларида Дисней геройларын гомосексуалистлар итеп ясаган. Гадәти булмаган рәсемнәрдә Алладин, Геркулес, Питер Пен һәм Смурфиклар ориентацияләрен үзгәрткәннәр. Кыскасы, әкият ялган булса да, гей-егетләргә менә дигән дәреслек.





Алексей МАМАЕВ

РЕКЛАМА



2015 елның икенче яртыеллыгына язылу дәвам итә. Почта бүлегенә ашыгыгыз һәм “Чаян”га язылыгыз!



Джим Бентон (Англия)




КҮҢЕЛЛЕ КУНАКЛАР

Чит ил басмаларыннан шаян рәсемнәр

МАТТИЧИНО (Италия)



Уолтер Хоммонд (АКШ)



Павел Константин (Румыния)





• • •

Табиб – авыруга:

– Сезгә аракы эчүдән тыелып торырга кирәк, саф һавада йөрергә, һәр көн иртән физик күнегүләр ясарга һәм көненә бер генә сигарет тартырга тәкъдим итәм.

Бер айдан соң авыру яңадан килә һәм табиб аннан сорый:

– Сез мин әйткәннәрне үтәдегезме?

– Берсеннән калганын барысын да: минем яшьтә тартырга өйрәнү авыррак икән шул.

• • •

– Кадерлем, син мине ратасыңмы?

– Үзең уйлап кара, яратмаган хатын белән мин егерме ел буе диванда, шушылай, бернәрсә эшләми ятар идемме?

• • •

– Минем хатын гомер буе мырлый: "Өстемә әйбер юк, өстемә әйбер юк!"

– Бир шуңа бер капчык бәрәңге, йөрсен күтәреп!

• • •

– Син нигә елыйсың?

– Китап бик кызганыч.

– Нинди китап соң ул?

– Зачет китабы...

• • •

– Алло! Бу модель агентствосымы?

– Әйе.

– Сез модельләргә күпме түлисез?

– Яхшы түлибез, ләкин параметрлары 90–60–90 булганнарны гына алабыз.

– Бу яктан минем проблемаларым юк, бөтенесе туры килә – буем да, яшем дә, авырлыгым да.

• • •

Ир кеше табибта:

– Сезгә физик нагрузка кирәк.

– Әйе, доктор, мин көн саен эшкә җәяү йөрим.

– Юк, ул гына җитми. Автобуста халык шыгрым тулы чакта йөреп карагыз сез.

• • •

Бер әби банкка килә дә, счетыннан бөтен акчасын ала һәм китеп бара. Биш минуттан яңадан килә һәм яңадан счет ача.

– Нишләп алай итәсез? – дип сорый банк хезмәткәре.

– Улым, мин санап кына карадым.



САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 11 (1823) 2015

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры
һәм баш редактор
Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ

Баш редактор урынбасары: Ринат АБЗАЛОВ
Баш редактор урынбасары, баш рәссам:
Александр АЛЁШИН
Үсеш бүлеге: Әдилә БАҺАВЕТДИНОВА
Марс САБИРОВ
Җаваплы секретарь: Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА
Бүлек редакторлары: Людмила САФИУЛЛИНА
Артём СУББОТКИН
Алмаз ХӘМЗИН
Лилия ӘХМӘТОВА
Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Ләйсән ФӘЛӘХОВА

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.
Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм
массакүләм коммуникацияләр
өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба
(Роскомнадзор)
идарәсендә теркәлде.

Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

Нәшер итүче: АО «ТАТМЕДИА»
Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2

«Чаян»га Татарстанда, Россиядә һәм
БДБда барлык элемтә
бүлекчәләрендә һәр айдан язылырга
мөмкин.

ТАТАРЧА «ЧАЯН»НЫҢ
ИНДЕКСЫ – 73488,
РУСЧАСЫНЫКЫ –
«ЧАЯН» («Скорпион») – 73489.
Айга ике тапкыр чыга.

Редакция фикере авторлар фикере белән тәңгәл килергә мөмкин.

Редакция материалларны
авторларның ризалыгыннан башка
редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен
реклама бирүче җаваплы.

Басма 16 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен чыгарыла.
«Чаян»нан икәнен күрсәтмичә
журнал әсәрләрен файдалану тыела.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
Басарга кул куелды: 10.06.2015 ел.
Гомуми тираж – 4003
(рус. – 2300, тат. – 1703)
Заказ О-1692
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Офсет ысулы белән басыла.
Басма табагы 2,1.
Учетн.-изд. табагы 3,1.

Белешмәләр өчен
телефоннар:
(843) 562-11-41,
562-32-24,
татмедиа тел./факс: 562-32-47.

16+

E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan.su

Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2,
ТР, Казан, 420066

Бәясе ирекле

Алмаз ХӘМЗИН

Маладис, Сәхиб!

Ничекләр генә мыскыл итеп бетерми Сәхибне хатыны. Җәберләп әйткән сүзләренә генә кара син аның: җебегән, уҗым бозавы, хәчтерүш, булдыксыз һәм тагын шундыйраклары... Кулыннан эш килми торган булса бу йорт-җирне кем җиткерер иде дә, тупырдап үсеп килүче өч малае каян килгән дип беләдер?.. Башкалар телендә гел мактауда гына йөри югыйсә. Вәт Сәхиб, ичмасам, булдыра, вәт маладис, дип кенә торалар авыл хатыннары да. Кәнишне мактарлык! Әнә еллык эш нәтиҗәләре буенча гел алдынгылардан санала, урып-җыюда, комбайнер буларак, берәүгә дә беренчелекне бирмәде, чәчүдә дә, тракторын ватмый-нитми генә йөртеп, хәтта район буенча югары урын яулап, мотоциклга лаек булды. Үткән елгы Сабантуйда батыр булып калмаса да, читтән килгән спорт мастерына гына бирешеп, икенче калды. Ә менә быел үзе авылларының сабантуен оештырды һәм аның алып баручысы да иттеләр үзен. Андый вазыйфаны теләсә кемгә ышанып тапшырмыйлар! Халыкта авторитеты югары аның... Бары тик хатынында гына юк. Бер ачуын чыгарганда кыйнап карасаң ничегрәк булыр икән, дип уйлап куйды ул. Әйтәләр бит: хатын-кызның ара-тирә бер җеннәрен тузгытып торырга кирәк, дип. Юктан чыккан сүз түгелдер ул. Ләкин... Ләкин суксаң, башың судтан чыкмаска мөмкин. Вәт бәләле булырсың. Ярый, алда күз күрер әле, диде дә ул, кызып барган Сабантуйны тагын да кыздырыр өчен мәйдан уртасына куелган агач атка печән тутырылган капчыгын күтәреп менеп кунаклады. Кулындагы микрофоннан бөтен мәйданны гөрелдәтеп, көр тавышын яңгыратты:


– Җәмәгать, капчык сугышын башлыйбыз. Кемнең башы яки йөрәге ике, менсен минем белән көчен сынарга!

Китте "сугыш". Үткән елгы батыр да кузладан очып төште, артыннан этеп менгезгән центнер ярымлы авылдашы, хәзер май заводы директоры Җәүдәтне дә мәтәлдерде. Ярый әле, җиргә борынын төрткәнче, тотып калдылар үзен. Югыйсә мае сөткә әйләнә иде. Алкаш Галимҗанны ул кузлада өч секунд та тотмады, сул яктан капчыгы белән муен тамырына тамызуы булды, тегенең башланган аракы шешәсе, кесәсеннән атылып чыгып, дусты сәрхүш Сәхи алдына барып төште. Житмәсә, бөкесе чыгып, калган сыекчасы да агып маташа иде. Әй җылады инде Сәхи моны күреп. Ә халык! Ә халык!!! Гү килә... Монысын да очыр, Сәхиб! Берочтан инвестор Минһаҗга да кундыр! Бир кирәкләрен! Юк, Сәхибне ияреннән бәреп төшерүче күренми әле!

Кызды Сәхиб, кем менә, шәхесенә карамый, суга да төшерә. Маңгаеннан агып төшкән әче тир пәрдәсе аркылы каршысына хатыны Рәмзинәнең менеп утыруын сизми дә калды ул. Рәмзинә, иренең селтәнү уңаеннан килгән капчык астында башын иеп калды да, шул уңай инерциясенә өстәп үз капчыгын тегенең уң колак тамырына тартты һәм, җиргә сикереп төшеп, ирен кочагына алды. Шунда Сәхиб хатынының аңа беренче мәртәбә мактап әйткән сүзләрен ишетте:

– Булдырдың, сөеклем, маладис! Күптән халыкның Минһаҗга ачуы килеп йөри иде. Кузланы тәхет дип белгән, бүтән менә алмас инде, бүлнискә апкиттеләр.


Мәйдан гөж килә! Сәхиб, Сәхиб, Рәмзинә!!!



Виктор ФЁДОРОВ




Иван УРГАНТ




Валентин ДРУЖИНИН (Россия)

Джонни ДЕПП




ХИД (Бөекбритания)

Сальвадор ДАЛИ



Хосе МАРТИНЕС (Испания)

ОБАМА белән ОЛЛАНД



Виталий ПОДВИЦКИЙ (Россия)